

Каберлек, зират (зәрәт-ләр), мазарлар - адәм баласынын сонгы йорты. Анын яныннан узган һәр кеше бу доньянын мәнге тvгеллеген исенә тошерә. Вафат булган әби-бабаларыбыз, туганнарыбыз, кылган гамәлләребез искә тошә. Бvген яшәгән йортыбыз ничек чиста булса, зиратларыбыз да жыештырылган, анын кабер рәшәткәләре буялган, чәчәкләр утыртылган булырга тиеш. Монын савабы да әйтеп бетергесез. Мордовия татарлары яшәгән авыллар жирле-гендә мәнгелек йортка карата булган игътибар коннән-кон арта бара. Халык тарафыннан да аларны тозеклəндерv буенча һәр елны кvп эшләр башкарыла. Ел саен бердәмләшеп омәләр ясау гадәте бар.  Зиратлар кипкән vләннәрдән, корыган куаклардан чистартыла, яна коймалар тотуда игелекле кешеләр ядәм итәләр. Мәсәлән, һәр ел Атюрьево районы Тенеш (Татарское Тенишево), Кадошкино районы Большие Поляны (мәктәп укучылары, укытучылары белән бергә) зиратларында, авылларнын эшкә яраган яше-карты субботникларга жыела. Бер сvз белән әйткәндә, авылда яшәvче һәр кеше бу эшкә vз олешен кертергә тырыша. Тагы, дини бәйрәм алдыннан, кvп авылларда туганнары каберлекләрен чистарту эше индивидуаль алып барыла. Сvз дә юк, һәрбер кеше туганнарынын каберлеген караштыра, жыештыра, ә килеп жыештыра алмаучыларнын?..

Ләмберә районы Аксен авылынын яна зираты һәрвакыт тәртиптә. Бу эштә эшмәкәр Рафик Айяз улы Фетхуллов, ике улы Рушан һәм Дамир белән кvрсәткән хезмәтләренен, хормәтләренен олеше зур. Аллаһы Тәгаләнен Рәхмәте булсын! Житмәсә, мәетне кvмv очен кабер такталары, башказыктан башка (шәһәрдән алып киләләрме, авылданмы) зиратта бар. Аларны жыелган сәдака акчасынын бер олешенә алдан әзерлиләр. Зират оендә дә кирәк-яраклар әзерләнеп куелган. Ә аксенлыларнын иске зиратларында яткан ата-бабаларын хормәт итә белvче аз. Зиратка барып керим дисән, каберлеккә vтv очен куак, vлән дингезен гизәргә кирәк, еллар дәвамында череп беткән агач чардуганнар, башказыклар аунап ята; корыган агачлар бар кvренешкә ниндидер тәртипсезлек ости. Ләмберә районы Пунят (Иняты),  Ромоданово районы Ләбәжә (Алтар) зиратларынын кайбер каберлекләре чистартылып тора, ә кайберләренен янына шулай ук vтv очен бик тә тырышырга кирәк. Башка якларда шундый хәл бармы икән?.. «Исәннәрнен кадерен бел, vлгәннәрнен каберен бел», дигән әйтем бар бездә. Зиратларны тәртиптә тоту кебек изге гамәлне традициягә кертv моһим. Якыннарыбызнын рухы шатланып ятсын очен яхшылык эшләргә кирәк дип уйларга урын бар бу жирдә.

Башка район авылларына кvз салыйк. Атюрьево районы татар авыллары зиратларында,

мәсәлән, Кыштыруда (Большой Шуструй), Аллаголда (Усть-Рахмановка) һәрвакыт тәртип. Субботник иттереп авыл халкы ата-баба каберлекләрен Тенештә жыештыралар, дидем. Ә калган авылларда һәрбер гаилә vз туганнарын кадерли һәм тирә-ягында караучысы булмаган кабер-лекләрне дә тәртиптә тоталар. Ковылкино районы Искил – Старое Аллагулово авылы зираты шулай ук һәрвакыт тәртиптә. Һәркем изге эшкә зур олеш кертә; авылда яшәvчесе дә, ерак шәһәрләрдә торучылары да ялга килгән чакта кемдер кабер осләрен чистарта, кемдер кипкән агачларны кисә, кемдер ботен чvп-чарны зираттан чыгарып тора, ә кемдер - чардак буи, койма, истәлек ташы тозәтә. Шулай ук Инсар, Ельник, Кочкурово, Рузаевка районнары авыллары, Дубенка районы Ломат авылы халкы да (башка районнарда да шундый ук хәл дип уйлыйм) борынгы бабаларын хормәтли. Исәннәрнен кадерен белеп, vлгәннәрнен каберләрен белеп гомер итә Мордовиянен бу татар авыллары халкы.
Зират – кадерләп сакланырга тиешле изге урын. Мәнгелек йортларыбызерактан ук похтәлеге, чисталыгы белән аерылып торса, чәчәккә кvмелеп утырса, нинди кvркәм була; кvнелләребезгә дә тынычлык урнаша, яшәргә дә рәхәтрәк була.

**Наилә Насырова**